| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>БИЛЯРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БИЛӘР АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2019 с. Билярск №103

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлегендә**
**муниципаль берәмлекнең җирдән**
**файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә**
**үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 8, 31 ст., "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып

**Биләр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Татарстан Республикасы, Биләр авыл җирлеге, Биләр авылы, Ульянов урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан 16:05:020103:209 кадастр номерлы җир кишәрлегенең территориаль зонасын, ОД1дән (күп функцияле иҗтимагый-эшлекле зона) Ж1 территориаль зонасына (индивидуаль торак төзелеше зонасы) үзгәртеп корырга. Үзгәртелгән территориаль зона күләме 0,2389 га тәшкил итә. Территориаль зонаның урнашу урыны Кадастр кварталы: 16: 05: 020103.

1.2 Татарстан Республикасы, Биләр авыл җирлеге, Биләр авылы, Ленин тыкрыгы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлегенең 16:05:000000:1281 номерлы территориаль зонасын (төньякка ориентация биргәндә), Ж1 (индивидуаль торак төзелеше зонасы) булган территориаль зонаны (авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм корылмаларын урнаштыру зонасы) СХ2гә үзгәртергә. Үзгәртелгән территориаль зона күләме 0,5000 га тәшкил итә. Бу территориаль зонаның урнашу Кадастр кварталы: 16: 05: 000000

2. Әлеге карарны Биләр авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Г.Г. Хәбибуллин**